ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2023 г. Казань № 375-24/кс-2023

«Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыяте өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 №10-67/кс карары белән ташландык суларны (өслектәге агып җыелган суларны) агызуга билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2024 елга төзәтү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, ташландык су агызуга (өслектәге агып җыелган суларны агызуга) 2024 елга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай керемenә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 15.11.2023 №48-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыяте өчен 2020-2024 елларга ташландык суларны (өслектәге агып җыелган суларны) агызуга тарифлар билгеләү турында» 20.11.2019 №10-67/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.10.2020 №129-22/кс-2020, 15.11.2022 №345-61/кс-2022 карарлары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат

ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.»;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.11.2019 №10-67/кс карарына
1 нче кушымта (Татарстан
Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2023 № 375-24/кс-2023
карары редакциясендә)

Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыяте өчен 2020-2024 елларга ташландык су (өслектәге агып җыела торган суларны) агызуга тарифлар

| т/с | Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу белән шөгыльләнүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Ташландык суларны (өске агынты суларны) агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 | | 2021 | | 2022 | | 2023 | 2024 | |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр |
| | Лаеш муниципаль районы | | | | | | | | | |
| 1 | «Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыяте (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 7,95 | 8,26 | 8,26 | 8,75 | 8,75 | 14,76 | 12,27* | 12,27 | 13,32 |

<*> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 №381-97/кс-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге